Кешене аңлыйсың килсә, урманга бар. (Г. Гыйльман)

5. ЗАДАНИЯ ДЛЯ ФОНЕТИЧЕСКОГО АНАЛИЗА

Җөмләдәге сүзләргә фонетик анализ ясагыз.

Як-якта, яшел стенадай булып, арыш басып тора; ерак та түгел, арыш арасында ялгыз көнбагышның сары башы күренә (И.Гази)

МИНОБРНАУКИ РОССИИ
ФЕДЕРАЛЬНОЕ ГОСУДАРСТВЕННОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ
«БАШКИРСКИЙ ГОСУДАРСТВЕННЫЙ ПЕДАГОГИЧЕСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ ИМ.М.АКМУЛЛЫ»

Институт филологического образования и межкультурных коммуникаций
Кафедра татарского языка и литературы

Направление 44.03.05 Педагогическое образование
(с двумя профилями подготовки)

Уровень образования: бакалавриат

Направленность (Профиль) «Родной (татарский) язык, литература и английский язык»

ФОНД ОЦЕНОЧНЫХ СРЕДСТВ

СОВРЕМЕННЫЙ ТАТАРСКИЙ ЛИТЕРАТУРНЫЙ ЯЗЫК. ЛЕКСИКА

1. Целью дисциплины является развитие профессиональных компетенций

ПК-1 готовностью реализовывать образовательные программы по учебному предмету в соответствии с требованиями образовательных стандартов

ПК-7 способностью организовывать сотрудничество обучающихся, поддерживать их активность, инициативность и самостоятельность, развивать творческие способности.

ОЦЕНОЧНЫЕ СРЕДСТВА ДЛЯ ПРОВЕРКИ СФОРМИРОВАННОСТИ КОМПЕТЕНЦИИ

Контрольная работа №1

1 бирем. Ф.Сафинның “Саташып аткан таң” романыннан алынган өзектән күчерелмә мәгънәдәге сүзләрне табыгыз, стилистик кулланылышларын аңлатыгыз.

Эш белән онытылып, көннәренең бер-бер артлы йотыла баруын да тоймый калды... Шактый бертөрлегә әйләнеп беткән көннәрен җанландырган бер вакыйганы искә ала да, Әхмәтсафа шаклар ката. Бу дөнья, бер карасаң, шактый зур, киң сыман. Шушы Хива якларын гына ал. Һәр ике якта диңгез сыман ком сахрасы җәйрәп ята. Чүл барысын да йотып барган кебек. Аерым бер кешегә ни сан – сәфәргә кузгалган зур-зур кәрваннар да кибәнгә төшкән инә сыман гына монда. Бер офыкка кереп күмелгәч, кемнең кайда йөргәнен белмәле түгел.

2 бирем. Бирелгән мисалларда күчерелмә мәгънәле сүзләрне табып, төрләрен билгеләгез һәм күчерелмә мәгънәнең нәрсәгә нигезләнеп барлыкка килүен аңлатыгыз.

Эскерткә җитәрәк кар сизелерлек тирәнәйде, җил сызып-сызып сырт-сырт көртләрне тыгызлап өйгән, бозлы тауга охшаган тәбәнәк эскерт юаш кына ялтырый иде. (А.Гыйләҗев) 2) Каенның куанычы да, Кайгысы да ак аның: Күпме күрдем ак каен буйлап Ак күз яше акканын. (Р. Миңнуллин) 3) Ләкин булган кадәргесен бик пөхтәләп тышлап, китап битләре керләнмәсен өчен көмеш кәгазьдән тоткыч ясап, кадерләп кенә саклый иде. (Ә. Еники) 4) Һарун белән Мансур тиз-тиз генә эшләрен бетерделәр дә, усал телләр күзенә эләккәнче, алданрак ашап алырга булдылар. (Н. Фәттах) 5) Бөтен шәһәр бәйрәм итә: һәрбер өй гаскәрләрне кунак итеп алды, туган өйләрендәге кебек сый-хөрмәт күрсәтте. (Г. Исхакый) 6) ... Ә зәңгәр күзлек, әйтерсең, тырнак астына энә тыга. (М. Мәһдиев) 7) Яхъя моның шулай килеп чыгуына колхозны гаепләде. (Ф. Садриев)

3 бирем. Кабу, бирү, тулу, басу, тамыр, тел, үзәк сүзләренең күпмәгънәле булуын мисаллар өстендә дәлилләгез.

4 бирем. Түбәндәге өзекләрдә үзара омоним булган сүзләрне табыгыз, төрләрен билгеләгез, җөмләдә кулланылыш үзенчәлекләрен әйтегез.

1) Берни дә күрмим, ишетмим,
Җир һәм галәм кап-кара.
Анаң күкрәгенә ятып, Йөрәген тыңлап кара. (И.Юзеев)

2) Ул баш әйтә: Син вагоннан төш хәзер,
Бик якынлашты кирәкле төш хәзер. (Г.Тукай)

3) Анда һәртөрле гаҗәпләр бар да бар: Кып-кызыл алтын шәһәр, җиз карьялар...(Г.Тукай)

4) Аз гына сабыр ит әле, и кариэм! Хәзер язам;
Уйласам аулымны, гакълымнан да мин хәзер язам. (Г.Тукай)

5) Нишләтергә кәҗәбезне? Аптыратты кәҗә безне. (Р. Миннуллин)

6) Тегермән әйләнә, әйләнсә дә, тартылмыйдыр ярма.
Мәшәкатьләнмә бушка көчәнеп, юл уртасын ярма. (Г. Тукай).

7) Ком тавында уйный Кадыйр, ясый ул әллә ниләр.
Комсыз түгел бит мин, нигә миңа
Малайлар “комсыз”, диләр (Ш. Галиев).

5 бирем. Әлеге мисалларда аерып бирелгән сүзләрнең омоним яисә күпмәгънәле булуын ачыклагыз. Омоним булса, нинди юл белән барлыкка килгәннәр?

1) Бураннар басылды,
Басылды, күк ачылды,-
Бигрәк зәңгәр икән күк,
Зәңгәр синең күзләр күк. (Ш. Галиев.)

2)Тик укытучы гына менә
Куйды бүген «икеле»
Берне түгел, икене!
Әни, бәлки, ачуланмас?
Юк шул, белмим, икеле. (Р. Миннуллин)

3) -Ике бабамны беләм...- дим.
-Мәгълүматларың тар, их, - ди,-
Бабаңнарда - ил язмышы, Алар үзе тарих , - ди. (Ш. Галиев)

4) Бабаемның туган көне,
Утыра түр башында:
Чигүле күлмәк кигән ул
Түбәтәе – башында. (Й. Җамалетдинова)

3 бирем. Оксюмороннарны табыгыз, стилистик ку лланылышларын аңлатыгыз.

1) Малай сискәнеп китә, әнисенең тавышы малайның дөньясын оныттырган саташулы өннең ләззәтен бетерә һәм шуңа күрә дә аның әнисенә ачуы чыга. (М. Галиев) 2) Малай исә шомлы ләззәткә чыдый алмый кычкырып елап җибәрә һәм тагын аръяк болынга таба торып йөгерә. (М. Галиев) 3) Авыру бу, беркемгә дә теләмим мин мондый авыруны, куркам мин бу газаплы бәхеттән... (М. Галиев) 4) Зифа буйлы купшы әфисәр Яшь хатынның сүзен ишетте. Гайрәтләнеп көяз башкисәр Каты ябып керде ишекне. (М. Җәлил) 5) Алдым менә җавап – кергәч гомер Картлыкның яшьлегенә... (Ә. Баянов)

Контрольная работа № 2.

1 бирем. Текстгагы сүзләрне генетик яктан тикшерегез, гарәп һәм фарсы сүзләренең мәгънәләрен сүзлек ярдәмендә аңлатыгыз, мөмкин булса, татар теленнән синонимнарын бирегез.

1) Шул иттифакыйлык болар арасында тагы әллә нәрсәне, мөнәсәбәттәге әллә нинди бер рәсмилекне җимерде... (Г. Исхакый). 2) Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан, Вә юлны тапмый һәрбер адашкан. (Г. Тукай). 3) Бервакыт чук-чук итеп сайрый ходайның кошлары; Китә җаннарны киселеп, ярып, садаи хушлары. (Г. Тукай). 4) Зирекле ишаны дигән исем татар дөньясының һәммә ягында мәшһүр иде. (Г. Ибраһимов).

2 бирем. Әлеге сүзләрне тематик төркемнәргә аерыгыз.

Алла, мөлкәт, мохит, сәлам, хөрмәт, хат, кыямәт, сәгать, шәраб, бәхет, кыяфәт, җомга, газап, кәгазь, якшәмбе, такта, гыйлем, мәктәп, җәдвал, шәй, нәшрият, бәдән, базар,

мәгърифәт, ятим, таҗ, фән, сәнәгать, җәннәт, гыйрфан, сәүдәгәр, кәеф, әдәби, сурәт, мәхәббәт, мал, фәлсәфи, хәрби, акшам.

3 бирем. Түбәндәге тексттан гарәп һәм фарсы телләреннән кергән берәмлекләрне аерыгыз, аларның кулланылыш активлыгын билгеләгез, яңадан телебезгә әйләнеп кайткан сүзләрне күрсәтегез.

1) Мөмкинме дини вә рухани бер мәдрәсәдә тәрбия кылынган җир фәрештәсе шәкертнең аракы эчүе? (З. Бигиев) 2) Безнең сөннәтче бабай Сәлман фарси хәзрәтләреннән мирас тарихы берләп сөннәтчелекне алса да. Әбугалисина хәзрәтләре тарафыннан тыйб гыйлеме, гыйльме симия вә гыйльме кимиягә иҗазәт алмаганга, әлбәттә, тыйб гыйльменең бу кадәр нечкәлекләрен белми иде. (Г. Исхакый) 3) Бүлмә эссе күк, бүлмә тыгыз күк тоела; тәрәзәгә китереп бәрә торган кар тавышы да Әхмәтнең рухында тагын бер яра ача иде. (Г. Газиз.) 4) Илаһи, син юмарт, ризык бирүче, Бер син, бар син, рәхим, гафу итүче. (Мөхәмәдьяр) 5) Кечкенә генә тәрәзәле караңгы гына мәчет үзенең сәләмә намазлыклары белән бик фәкыйрь төсле күренсә дә, яшь мулланың сузып кына, яхшы гына кыярәт белән имам булуы шактый күңелгә тулды. (Г. Исхакый).

4 бирем. Текстгагы рус һәм көнбатыш Европа телләреннән кергән сүзләрне табып, аларның тематик һәм генетик төркемчәләрен билгеләгез.

1) Лотфуллага коммуналь йорттан фатир бирделәр. (Г. Ахунов) 2) Сул якта рәт-рәт скамьялар тезелеп китеп, бик зур бер театр партеры шикелле күренеш тәшкил итә. (Ф. Әмирхан) 3) Бу инде иртән йокыдан торгач, һичшиксез, илле грамм ак күмәч өстенә егерме грамм май ягып, бер калак джем кабып, тиз эри торган Бразилия кофесын эчеп эшкә килә торган кеше. (М. Мәһдиев) 4) Проект расларга, ул бер аспирант белән районга китү ягын карады. (М. Мәһдиев)

5 бирем. Җөмләләрдәге сүзләрнең кайсылары гомумхалык сүзләре, кайсылары иҗтимагый яисә территориаль яктан чикләнгән?

1)Чит илдән кайтканнар мактанып йөргәнгә дә кызыкмыйм. Күпләр мине үртиләр, акчаң бар бит, нигә аны кызганасың, нигә загранитсыны күреп, дөнья белән танышып кайтмыйсың, диләр. (Т. Миңнуллин) 2) Татарстанның дәүләт милке белән идарә итү комитетында эшләнгән методика буенча, 1993 елның январеннан ваучер һәм исемле хосусыйлаштыру вкладларына фиксацияләнгән, ягъни тотрыклы, үзгәрми торган бәяләр билгеләнгән. («Татарстан») 3) Егетләрнең рульдә утырганы тәрәзәдән муенын сузып: — Бер «чистай малае» абзый, яме? Ату келтерефүн арбаңны этеп тә тору юк. Бушка тир агызмыйлар бездә. Әллә айдан сикердеңме син! (Н. Гыйматдинова) 4) Хуҗалар: — Майашлар әзер, утырыгыз, туганнар! (Татар халык җыры) 5) Туктат шул азвы чәпелдәтүеңне, төкереп ат шул хәшәрәтне. Игътибар белән тыңла, комик, хәзер үк Ялагай янына сыптыр. (Р. Хаҗиев)

Вопросы для устного опроса

1. Моносемия и полисемия, пути возникновения полисемии в лексической системе.
2. Прямое и переносное значение слов.
3. Виды переноса значений: метафора, метонимия, синекдоха.
4. Виды метафор.
5. Перенос значения по функции.
6. Виды омонимов по образованию, по лексико-семантическому и грамматическому значению.
7. Возникновение омонимов.
8. Синонимы.

9. Возникновение синонимов.
10. Антонимы, их лексико-семантические особенности. Энантиосемия.
11. Выразительные средства, основанные на антонимах (оксюморон, антитеза).
12. Лексический состав родного языка с точки зрения происхождения.
13. Заимствования из персидского и арабского языков.
14. Заимствования из русского и из европейских языков.
15. Кальки в татарском языке.
16. Лексичекий состав родного языка с точки зрения сферы употребления.
17. Лексический состав родного языка с точки зрения активности употребления.
18. Экспрессивно-ситлистические пласты татарского лексического фонда.
19. Фразеологическая система родного языка.
20. Этимология.
21. Ономастика.
22. Лексикография.

Контрольные вопросы

1. Что такое слово? (дать определение понятию слово).
2. Как вы понимаете лексическое значение слова?
3. Слово и понятие, их взаимоотношение.
4. Номинативная функция слова.
5. Что такое этимология?
6. Назовите разделы лексикологии.
7. Назовите виды лексических значений по отношению их к предметам, явлениям окружающей действительности.
8. Назовите виды лексических значений по отношению их к мысли (сознанию).
9. Назовите виды лексических значений, исходя из их различий во взаимной связи.
10. На какие три вида делятся метафоры родного языка?
11. Какие вы знаете виды омонимов, исходя из особенностей произношения и написания?
12. Что такое абсолютные синонимы?
13. Объясните, почему много антонимических пар в сосотаве прилагательных и наречий?
14. На какие тематические группы можно разделить общетюркскую лексику в татарском языке?
15. Выразите своё отношение к заимстовованной лексике в татарском языке.
16. Какие вы знаете виды калькирования? Объясните на своих примерах.
17. Какие слова объединяются в профессиональную лексику?
18. Что такое жаргонная и арготивная лексика?
19. Что лежит на основе подразделения лексики на активную и пассивную лексику?
20. Назовите отличительные признаки фразеологизмов от словосочетаний.
21. Назовите основные темы в разделе Лексики образовательной программы по Татарскому языку в соответствии с требованиями образовательных стандартов
22. Назовите основные приемы организации сотрудничества обучающихся, поддержки их активности, самостоятельности на уроках лексики.
23. Назовите основные приемы развития творческих способностей учащихся на уроках татарского языка.

Тесты

Лексикология нәрсәне өйрәнә?

a) телнең аваз составын
b) сөйләм төзелешен
c) телнең сүзлек составын

Белү мөшкел кирәк кемне сөяргә,
Үзең аусаң да, аудармый сөяргә. (Г.Тукай)
Г.Тукайның түбәндәге шигырь юлларында омонимның кайсы төре файдаланылган?

a) омофоннар
b) омографлар
c) омоформалар

Алтын сүзе кайсы сүзтезмәдә күчерелмә мәгънәдә?

a) алтын балдак
b) алтын куллы
c) алтын кашык

Кече сүзенең даими антонимын билгеләгез:

a) олы
b) дәү
c) зур

Әлеге сүзләрнең кайсысы атаманы белдерә?

a) песәй
b) авыл
c) аергыч

"Мактану" мәгънәсен кайсы фразеологизм белдерә?

a) тетмәсен тетү
b) сабын күбеге очыру
c) терсәкне тешләү

Синонимик рәттәге төп сүзне билгеләгез: бәйсез, азат, хөр

a) хөр
b) бәйсез
c) азат

"Балалар дөньясы" кибетләрендә төрле фирмалар җитештергән төрле уңайлы җайланмаларны сайларга, кечкенә сабыйлар өчен ползунки, боди кебек киемнәр дә алырга мөмкин. ("Шәһри Чаллы" газетасыннан)
Бу җөмләдә "боди" сүзе:

a) архаизм
b) неологизм
c) тарихи сүз

Кайсы төркемдә антонимнар бирелгән?

a) тар, киң
b) Айтуган, ай туган
c) йөгерә, чаба

Бирелгән сүзләр арасыннан диалекталь сүзне билгеләгез:

a) көнбагыш
b) кофе
c) карагат

Фонетика, өчпочмак, фокус, хәл кебек сүзләр кайсы төркемгә карый?

a) атамалар
b) гомумхалык сүзләре
c) диалекталь сүзләр

Лексика нәрсәне өйрәнә?

a) авазларны һәм хәрефләрне;
b) сүзләрнең ясалышын һәм төрләнешен;
c) сүзтезмә һәм җәмләләрне;
d) сүзләр җыелмасын

Сүзнең лексик мәгънәсен билгеләгез.

a) өстәл – исем;
b) өстәл – җөмләдә ия;
c) өстәл – агачтан ясалган өй җиһазы;
d) өстәл – җөмләдә хәбәр

Болар үзара нинди сүзләр?

a) Баш (кеше башы, агач башы); аяк (кеше аягы, өстәл аягы).
b) синонимнар;
c) бер мәгънәле сүзләр;
d) күпмәгънәле сүзләр

Нинди сүзләр омонимнар дип атала?

a) әйтелеше төрле, мәгънәсе бер үк сүзләр;
b) капма- каршы мәгънәле сүзләр;
c) язылышы бер үк, әйтелеше төрле сүзләр;
d) язылышы яки әйтелеше бер, мәгънәсе төрле сүзләр

Фразеологик берәмлекне табыгыз

a) Бүгенге эшне итрәгәгә калдырма.
b) Өрми дә, җибәрми дә. Ул нәрсә?
c) Бүрәнә аша бүре куу.
d) Ямьле да соң безнең Идел буйлары!

Болар нинди сүзләр?

a) Казый, зәхмәт, талак, ярлык, золым.
b) неологизмнар;
c) архаизмнар;
d) гомумкулланыштагы сүзләр

Искергән сүзнең төрен билгеләгез: **берлән**

a) тарихи сүз
b) архаизм

Телебезгә башка телләрдән кергән сүзләр ничек атала?

a) алынма сүзләр
b) архаизмнар
c) неологизмнар

Синонимнарны табыгыз.
катлаулы, четерекле, буталчык, чуалчык
ошый, охшый, охшаш, кебек

a) бит (кеше бите), бит (кисәкчә), бит (дәфтәр бите)}

Синонимик рәттә уртак төшенчәне белдергән сүз ничек атала?

a) доминанта сүз
b) полисемия
c) лексика

Аерып бирелгән сүзләрнең күпмәгънәле яисә омоним булуларын ачыклагыз.
Авырудан сызу – таблица сызу

a) күпмәгънәле сүзләр
b) омонимик сүзләр

Кайсы төркемдә антонимнар бирелгән?

a) тәүге ,беренче
b) тар, киң
c) кызырган, кыз арган

Бирелгән сүзләр арасыннан диалекталь сүзләрне билгеләргә

a) мәктәп
b) синоним
c) ызба

Омонимның төрен билгеләргә:
Таба югалган! Кайсыгыз таба?

a) омоформа
b) омограф
c) омофон
d) саф омонимнар

Аңлашылмый торган сүзләрнең мәгънәләрен кайдан карап белеп була?

a) башка телдәге сүзләрдән;
b) аңлатмалы сүзлектән;
c) телара сүзлектән.
d) орфографик сүзлектән

Гөман сүзенең мәгънәсен аңлатыгыз:

a) гөнаһ;
b) фараз, юрау;
c) ялган

Сүзләр нинди мәгънәле була?

a) бер мәгънәле;
b) күп мәгънәле;
c) бер, күп, туры , күчерелмә мәгънәле

Полисемия дип нәрсә атала?

a) өстәмә мәгънәле сүз;
b) күп мәгънәле сүз;
c) бер мәгънәле сүз

Күчерелмә мәгънәле сүз дип нәрсә атала?

a) бер предметны аңа охшаган икенче предметтан аеручы сүз;
b) бер предмет яки күренешкә аңа охшаган икенче предмет яки күренеш билгеләрен күчереп кую;
c) икенче урынга күчереп куелган сүзләр

Омоним дип нәрсә атала?

a) күп мәгънәле сүзләр;
b) аваздаш сүзләр;
c) күчерелмә мәгънәле сүзләр

“Куеныңда таш саклау” тезмәсе нинди лексик күренеш?

a) гади сүзтезмә;
b) фразеологик әйтелмә;
c) күчерелмә мәгънәле сүзләр

Омоним һәм полисемия арасында нинди аерма бар?

a) аерма юк;
b) полисемия нигезендә охшашлык ята, омонимнар мәгънәсендә охшашлык юк;
c) полисемия нигезендә охшашлык юк,омонимнарда охшашлык бар}

Синоним дип нәрсә атала?

a) капма – каршы мәгънәле сүзләр;
b) аваздаш сүзләр;
c) әгънәдәш сүзләр

Антоним дип нәрсә атала?

a) мәгънәдәш сүзләр;
b) аваздаш сүзләр;

c) капма- каршы мәгънәле сүзләр}

Алынма сүзләр дип нәрсә атала?
a) башка телләрдән кергән сүзләр;
b) бик күп телләргә кабул ителгән сүзләр.
c) рус теленнән кергән сүзләр}

Фразеологик әйтелмә составында ничә сүз булырга мөмкин?
a) ике сүз;
b) өч яисә дүрт сүз булырга мөмкин;
c) икедән артык сүз була}

Фразеологик әйтелмә дип нәрсә атала?
a) күчерелмә мәгънәдәге төзелмәләр;
b) сүзтезмәләр;
c) үзара тыгыз бәйләнгән берничә сүздән төзелгән күчерелмә мәгънәгә ия төзелмә}

Халыкара сүзләр дип нинди сүзләр атала?
a) чит телдән кергән сүзләр;
b) күп телләргә кабул ителгән сүзләр;
c) гомумхалык сүзләре}

Неологизм нәрсә ул?
a) искергән сүзләр;
b) яңа сүзләр;
c) алынма сүзләр}

Лексикография дип нәрсә атала?
a) сүзлекләр төзү турындагы фән;
b) сүзлекләр җыю турындагы фән;
c) сүзләрне җыю, тәртипкә салу}

Омофон дип нәрсә атала?
a) бер төрле языла, ләкин әйтелештә аерма булган сүзләр;
b) бер төрле яңгырый, ләкин аерым языла;
c) мәгънәдәш сүзләр}

Ономастика нәрсәне өйрәнә?
a) кеше исемнәрен;
b) географик атамаларны;
c) ялгызлык исемнәрне}

Көймә комга терәлү, агач атка атландыру, борын күтәрү- нинди лексик күренеш?
a) фразеологик әйтелмә;
b) гади сүзтезмәләр;

c) күчерелмә мәгънәле сүзләр}

Сүзлекләр ничә типка, төп төргә бүленә?
a) орфографик;
b) ике телле;
c) аңлатмалы һәм телара сүзлекләр}

Микротопонимика нәрсәне өйрәнә?
a) ялгызлык исемнәрне;
b) географик атамаларны;
c) аерым төбәк кешеләре өчен генә билгеле географик атамаларны}

“Әдәбият белеме сүзлеге” нинди төргә карый?
a) телара;
b) аңлатмалы

Антропонимика нәрсәне өйрәнә?
a) географик атамаларны;
b) җирле географик атамаларны;
c) кеше исемнәрен

Архаизм дип нәрсә атала?
a) яңа сүзләр;
b) хәзерге көндә булган предмет, күренешләрнең искергән атамалары;
c) алынма сүзләр}

Сүзнең дөрес язылышын кайсы сүзлектән карап белеп була?
a) аңлатмалы сүзлек;
b) орфографик сүзлек;
c) телара сүзлек

Топонимика нәрсәне өйрәнә?
a) кеше исемнәрен;
b) географик атамаларны;
c) ялгызлык исемнәрне

Диалекталь сүзләр дип нинди сүзләр атала?
a) үзенчәлекле сүзләр;
b) билгеле бер профессия кешеләре куллана торган сүзләр;
c) җирле сөйләм сүзләре

Профессиональ сүзләр дип нинди сүзләргә әйтәбез?
a) фән, техника һәм башка өлкәләргә караган сүзләр;
b) билгеле бер профессия кешеләре тарафыннан кулланыла торган сүзләр;

c) профессияне белдерүче сүзләр

Таш йөрәк фразеологик әйтелмәсенең төгәл мәгънәсен аңлаткан сүзне күрсәтергә.
a) миһербансыз
b) саран
c) көчле
d) тәртипсез

Татар теленә гарәп теленнән кергән сүзләрне билгеләргә
a) рекорд, чемпион, футбол
b) дәфтәр, әти, абый
c) мәгариф, сәлам, галим
d) амбар, атаман, алтын}

– Нишләп балтасы суга төшкән кеше кебек утырасың? (Н. Дәүли) җөмләсендәге тотрыклы сүзтезмәнең мәгънәсен күрсәтегез:
a) моңсуланып, боегып утыру
b) шатланып, елмаеп утыру
c) аяк киемен салып утырып тору
d) су (елга) янында утыру}

Әдипләребез үз әсәрләрендәге һәр кешене – персонажны үз баласы, үз нәселе санап, берсенең исемен икенчесенә кушмаганнар (Х. Сарьян) җөмләсендә рус теле аша кергән һинд-европа алынмасын күрсәтегез.
a) әдипләребез
b) әсәрләрендәге
c) персонажны
d) нәсел

Җөмләдәге неологизмны күрсәтегез: Дивардагы көнсанардан бүгенге битен ертып алды. (Б. Камалов)
a) битен
b) дивар
c) көнсанар
d) бүгенге

Түбәндәге мисаллардан синоним вариантны күрсәтегез.
a) вак, бәләкәй, нәни, кечтеки, кечек
b) васыять, кәгазь, китап, үтенеч
c) керәшә, саескан, торна, әтәч
d) алма-лама, ай-ай!, буялган- бу ялган}

Түбәндә бирелгән мисаллар арасыннан кәкре каенга терәту фразео-логизмына синоним сайлап алыгыз.
a) теле телгә йокмый
b) килмәгән җире юк
c) төпсез чанага утырту
d) тел белән тегермән тарту}

Билгеләмәне дөрес итеп тәмамлагыз: Сузлекләрне җыю, тәртипкә салу һәм сузлекләр төзу ...
a) лексикология дип атала

b) лексикография дип атала
c) пиктограмма дип атала
d) морфемика дип атала}

Мактанчык, һавалы, әрсез сүзләре тыйнак сүзенә карата нинди мәгънә мөнәсәбәтендә торалар?
a) парлы сүз ясыйлар
b) бу сүзләр тыйнак сүзенә антоним
c) бу сүзләр тыйнак сүзенә омоним
d) бу сүзләр тыйнак сүзенә синоним}

Җөмләдә аерып бирелгән сүз кулланылыш сферасы ягыннан кайсы төркемгә керә:
Өстәлне төрле-төрле *тәкәләр*, каймаклар, *чәкчәкләр* бизи иде. (А. Гыйләҗев)
a) диалекталь сүз
b) неологизм
c) архаизм
d) бу сүзнең лексик мәгънәсе юк}

Фразеологик берәмлекне күрсәтегез.
a) телсез (теле төшкән) сәгать
b) телсез гармун
c) телсез калу
d) телсез Кеше

Кайсы төркемдә синонимнар бирелгән?
a) табу, эзләү
b) азатлык, бәйлелек
c) качу, яшеренү
d) киенү, чишенү

Фразеологик әйтелмәләрне билгеләгез.
a) авыз еру, авыз йомып калу, авыздан өзү
b) зирәк, зиһенле, тапкыр, акыллы
c) карт аю - картаю, карат - кара ат, яра (утын яра) - яра (җәрәхәт)
d) ал - арт, дус - дошман, югары – түбән

Антонимнарны билгеләгез.
a) якты-караңгы, тиз-әкрен, керә-чыга
b) аз гына, бераз гына, тамчы гына
c) ал (китапны), ал (яулык), ал (алгы як)
d) күз (күрү органы), күз (икмәктәге тишек), күз (шәл бәйләгәндә элмәк)

Кайсы рәттәге фразеологик әйтелмәнең татарча варианты туры килми?
a) руки не доходят – кул җитми
b) как две капли воды – ике тамчы су кебек
c) прийти с пустыми руками – буш кул белән килү
d) сбиться с ног – бар көченә}

Омонимнар ул –...
a) охшаш мәгънәле сүзләр
b) капма-каршы мәгънәле сүзләр
c) әйтелеше бертөрле, мәгънәләре башка булган сүзләр

d) күп мәгънәле сүзләр}

Бердәй профессия, көнкүреш шартларында, уртак интереслар белән бергә вакыт үткәрүче бер иш кешеләр сөйләмендәге үзенчәлекле сүзләр җыелмасы ничек атала?

a) Диалекталь лексика
b) Һөнәрчелек лексикасы
c) Жаргон сүзләр}

Лексикология фәне нәрсәне өйрәнә?

a) телнең грамматикасын
b) телнең сүзлек составы
c) сүзнең лексик мәгънәсен

Лексика сүзенең аңлатмасын тап

a) сүзләр төзү турындагы фән
b) авазларны өйрәнә торган фән
c) нинди дә булса бер телдәге яки диалекттагы барлык сүзлә

Килеп чыгышы ягыннан сүзлек составына керә.

a) гомумтөрки сүзләр,алынма сүзләр,интернациональ сүзләр
b) гомумхалык һәм һөнәрчелек сүзләре
c) актив, пассив сүзләр

Фонетика, водород, керем – бу нинди сүзләр?

a) гомумхалык сүзләре
b) һөнәрчелек сүзләре
c) диалект сүзләр

Пассив сүзләрне табыгыз.

a) матур, яхшы
b) ипи, әни,чәй
c) күмхуҗ, гаскәри, олтан

Ошбу сүзенең бүгенге көндә кулланылган вариантын табыгыз

a) бу
b) шундый
c) монда

Күз ачып йомганчы фразеологизмның дөрес мәгънәсен табыгыз

a) ялганлау
b) шатлану
c) бик тиз

Дөньядагы барлык сүзлекләр нинди ике төргә бүленә?

a) энциклопедик һәм филологик
b) тәрҗемәи һәм телара
c) филологик һәм аңлатмалы

Түбәндәге билгеләмәгә туры килгән тропны күрсәтегез “Алыштыру, күренеш, гамәл, сыйфатны үз исеме белән әйтмичә, икенче бер сүз белән белдерү”:

a) метонимия
b) метафора
c) синекдоха

Нинди сурәтләү чарасы кулланылган:
Шау-шу иле.
Ридикюльләр
Кәрзин белән сатулаша лотокларда . (Р.Фәйзуллин “Базарда”)

a) Эпитет
b) Метонимия
c) Синекдоха

Омонимнар –

a) бердәй яңгырашлы, язылышлы, ләкин төрле мәгънәле сүзләр
b) бер төрле язылып, икенче төрле әйтелә торган сүзләр
c) капма-каршы мәгънәле сүзләр

Чагыштыру –

a) күплек урынына берлек, бөтен урынына кисәкне яки, киресенчә, берлек урынына бөтенне куллану.
b) бер күренешне икенче предмет янына куеп, шуңа охшатып, янәшә китереп сүрәтләү.
c) алыштыру, күренеш, гамәл, сыйфатны үз исеме белән әйтмичә, икенче бер сүз белән белдерү.

Метафора –

a) алыштыру, күренеш, гамәл, сыйфатны үз исеме белән әйтмичә, икенче бер сүз белән белдерү
b) күплек урынына берлек, бөтен урынына кисәкне яки, киресенчә, берлек урынына бөтенне куллану
c) күренешне икенче предмет янына куеп, шуңа охшатып, янәшә китереп сүрәтләү

Хәзерге җанлы сөйләмнән төшеп калган, искергән сүзләрне, борынгы грамматик формаларын _____ диләр.

a) тарихи сүзләр
b) неологизм
c) архаизм

Яңалыкны аңлатучы сүзләр –

a) неологизмнар
b) тарихи сүзләр
c) архаизмнар

Матур әдәбиятта икенче бер тел сүзләрен куллану.

a) архаизм

b) варваризм
c) профессионализм

Аерым төбәкләрдә генә яши торган, уртак милли телгә үтеп кермәгән шивә элементларын нәрсәсәр дип йөртәләр?
a) варваризмнар
b) эвфемизмнар
c) диалектизмнар

МИНОБРНАУКИ РОССИИ
ФГБОУ ВО «Башкирский государственный педагогический университет им. М. Акмуллы»

Институт филологического образования и межкультурных коммуникаций

ФОНД ОЦЕНОЧНЫХ СРЕДСТВ

Б1.В.02.03 СОВРЕМЕННЫЙ ТАТАРСКИЙ ЛИТЕРАТУРНЫЙ ЯЗЫК. СИНТАКСИС СЛОЖНОГО ПРЕДЛОЖЕНИЯ

для направления подготовки

44.03.05 Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)
направленность (профиль) «Родной (татарский) язык, литература и английский язык»

квалификация выпускника: бакалавр

3. Целью дисциплины является *развитие профессиональных компетенций*:

ПК-1 готовностью реализовывать образовательные программы по учебному предмету в соответствии с требованиями образовательных стандартов;

ПК-9 способностью проектировать индивидуальные образовательные маршруты обучающихся.

ОЦЕНОЧНЫЕ СРЕДСТВА ДЛЯ ПРОВЕРКИ СФОРМИРОВАННОСТИ КОМПЕТЕНЦИИ

6. ТЕСТОВЫЕ ЗАДАНИЯ

Кушма җөмлә эчендәге җөмләләр арасындагы семантик мөнәсәбәтне дөрес билгеләгез
Фотография – сәнгать ул, сез аны аңламыйсыз һәм аңламаячаксыз да.
параллель күренешләрне белдерәләр
эзлекле күренешләрне белдерәләр
соңгы җөмлә алдагысының эчтәлеген тулыландырып килә
сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәттә торалар

Бәйләүче чараның синонимик вариантын күрсәтегез. *Үзең яхшы, үзеңнән сүзең яхшы*
шуңа күрә, әмма, ләкин
бары тик, ә, мәгәр
ләкин, ә, мәгәр
яисә, шулай ук, тагын

Адәм сөйли, язмыш көйли. Каршылык интонациясе шуны белдерә
җөмләләр үзара кискен каршы куела
бер-берсенә җиңелчә каршы кую бар
кара-каршы куеп чагыштыру
җыю-санау мөнәсәбәте

Юл аркылы чыкканда, кызлар, кинәт туктап, башта сулга, аннан уңга карадылар һәм, машина күренмәгәч, бөтен көчкә йөгерделәр. Бу:
катлауландырылган гади җөмлә
тезмә кушма җөмлә
аналитик иярченле кушма җөмлә
синтетик иярченле кушма җөмлә

Әйтәм лә йөзеңдә нурлар уйный, имтиханда яхшы билге алгансың икән.
Иярчен җөмлә баш җөмләгә нинди чара белән бәйләнгән:
көттерү паузасы
теркәгеч сүз
ялгызак мөнәсәбәтле сүз
ияртүче теркәгеч

Иярчен максат җөмләнең
синтетик төрләре генә була
аналитик төрләре генә була
аналитик һәм синтетик төрләре була
суперсинтетик төрләре була

Хәл фигыль формасы туктар-туктамас функциональ яктан нинди җөмлә төрен ясауда катнаша

иярчен вакыт җөмлә
иярчен рәвеш җөмлә
иярчен урын җөмлә
иярчен кире җөмлә

Бу җөмләдә ничә предикатив нигез бар
Ат өстендә бу юлы ни эшли дип әзерләп торган сылу кыз юньләп күрми дә калды: җылкычының койрыгы каядыр ташланды, яшен тизлеге белән бәрелешү булып алды, көтүче ат өстеннән юк булды, егылып тапталдымы, башка маллар һәммәсе төрле якка, тыр-тыр килеп, дулап, сикереп таралдылар, ачык мәйданда бер-берен өстерәгән берсе иярле ике ат калды.
6
9
8
7

*Бер төрле кешеләр бар: син аларга дус булсаң, алар каршында галим дә син, мөхәррир дә син, әмма бераз салкынлык булса, алар синдә булган фазыйләтне (талантны) уйларга да куркалар.(Г.Тукай).*Бу җөмләнең төрен билгеләгез.Ул:
тиңдәш ияртүле күп иярченле кушма җөмлә
күп тезмәле кушма җөмлә
катнаш кушма җөмлә
берничә төрле бәйләнешле күп иярченле кушма җөмлә

Текстның грамматик бөтенлеге түбәндәге кайсы чараны кабул итми?
ияртүче теркәгечләрдән гүя, чөнки
ялгызак мөнәсәбәтле сүзләр
парлы мөнәсәбәтле сүзләр
парсыз тезүче теркәгечләр

Түбәндәге җөмләдә астына сызылган сүзләрнең синтаксик функцияләрен билгеләгез *Иң түргә, өстәл башына, кияү белән кызны утырттылар.*
аерымланган хәл
урын хәле
аныклагыч
аныкланмыш

Басыбрак тотмасаң, кәләпүшеңне алып китәргә тора җөмләсендәге кушма фигыль хәбәрнең модаль мәгънәсен билгеләгез
чарасыз теләкне белдерү
ниятләүне белдерү
ихтималлыкны белдерү
тәкъдимне белдерү

Бер үк вакытта булган ике эшне белдерә торган тезмә кушма җөмләне аерыгыз
Мин әкият сөйлим, балалар тыңлый
Кояш чыга, яңгыр койды
Болыт килде, яңгыр койды
дөрес җавап юк

Түбәндәге иярчен кушма җөмләләрнең кайсысы синтетик төзелешле?
Кошлар кайта: яз җиткән

Яз җиткәч, кошлар кайта
Яз җитә, шуннан кошлар кайта
дөрес җавап юк

Тик аналитик ияртү бәйләнеше чараларыннан торган төркемне күрсәтегез:
кем-шул, әллә-әллә
чөнки, гүя, ки
ләкин, әмма, тик
да, дә, та, тә

Ягъни теркәгече нинди иярчен җөмләдә була
иярчен сәбәп җөмләдә
иярчен хәбәр җөмләдә
иярчен аныклагыч җөмләдә
дөрес җавап юк

Иярчен җөмләнең төрен билгеләгез *Кемнең эше юк, шуның ашы юк.*
иярчен ия җөмлә
иярчен тәмамлык җөмлә
иярчен аергыч җөмлә
иярчен хәбәр җөмлә

Текстның бер төре булган теземнең бүлекләре арасында кайсысы артык
санау бүлеге
тезү бүлеге
төп бүлек
дөрес җавап юк

Кайсы тезмә кушма җөмләдә сызык куела
Дөнья матур /?/ яшәү күңелле
Мин барам /?/ ул өйдә юк
Җил дә юк /?/ һава бөркү
Әле яңгыр ява /?/ әле кар ява

Җөмлә өйрәнүдә текст нинди синтаксик юнәлешләрдән тора
гади җөмлә синтаксисы
кушма җөмлә синтаксисы
текст синтаксисы
бар җаваплар да дөрес.

Утыр аулакка, кайда һич кеше юк. Бәйләүче чараны күрсәтегез
теркәгеч сүз
төп ялгызак мөнәсәбәтле сүз
алынма ялгызак мөнәсәбәтле сүз.
теркәгеч

Фигыль фомасы туктар-туктамас нинди җөмлә төрен барлыкка китерүдә катнаша
иярчен вакыт җөмлә
иярчен рәвеш җөмлә
иярчен урын җөмлә.
иярчен сәбәп җөмлә

Иярчен рәвеш җөмләне барлыкка китерүче чара
 юкса
 –мыни/–мени сорау кушымчалары
 шунда
 дөрес җавап юк

Ялыныплар сорагач, сүзне тыңларга булдылар(вәгъдәләрендә торырга булдылар). Иярчен сәбәп җөмләне барлыкка китерүче чараны сайлап алыгыз
 – гач(ганга)
 –сын дип
 –у белән
 дөрес җавап юк

Аналитик чаралар
 көттерү паузасы
 теркәгеч сүзләр
 мөнәсәбәтле сүзләр
 барысы да дөрес

Аналитик чараларга кайсысы керми
 чөнки,шунда
 янәшә тору
 килеш кушымчасы
 –кән хәлдә

Бу җөмләдә ничә предикатив нигез бар
Хәзер дә күз алдында: иң түргә мулла җизнидән дә югарыга, бер таза кеше утырган өстендә әллә нинди, мужик баендагы кебек манчестерлы казаки, башында укалы такыя, кулында зур гына , акайган гына мужик килешенеке кебек яулык.(Г.Исхакый"Остазбикә")
 4
 5
 6
 7

Ни йөзең белән килеп күрендең, ни әйтергә теләдең җөмләсендә тиңдәш кисәкләр үзара ничек бәйләнгәннәр
 җыючы теркәгечләр һәм каршы кую интонациясе
 кабатланып килүче бүлүче теркәгече һәм санау интонациясе
 санау интонациясе
 каршы кую интонациясе

"Шул ук Җиһангир , кара кәләпүш астындагы җитү чәчләрен ипли төшеп, шыгырым тулы залга карады, күңелсезләнеп нидер әйтергә теләде, ләкин мәҗлес шаулаша иде, төрле яктан нидер сөйләргә теләп кычкырырга тотындылар" җөмләсе нинди төргә керә
 күп иярченле кушма җөмлә
 күп тезмәле кушма җөмлә
 катнаш кушма җөмлә
 катлауландырылган гади җөмлә

Төмән-Тубыл тарафларында татарлар яшәгән төшләрдә йөрүләр шуны күрсәтте. Бу җөмлә эчендә иярчен җөмләнең төрен билгеләгез

иярчен тәмамлык җөмлә
иярчен аергыч җөмлә
иярчен рәвеш җөмлә
иярчен урын җөмлә

Юлда көпчәк сынуны, Бөгелмәдә аны көч-хәл белән рәтләткәч, аккумулятор утырып,машина кабынмый газаплануны, һәм профессорлар, доцентлар, ассистентлар, җыйнаулашып, йөк машинасын арттан этә-этә мотор кабызучыларны артык тасвирлауның хаҗәте юктыр кебек. Ничә предикатив үзәге бар
3
4
5
6

Түр башында чигелгән сөлге астында тальян гармун тора.Шушы гармунда әбекәйнең бөтен кайгысы.Ул аңарда, "шундый матур итеп уйный белә". Бу өзектә нинди җөмләләр бар
боерык, хикәя җөмләләр
боерык, тойгылы җөмләләр
хикәя, тойгылы
барысы да дөрес

Үзең яхшы, үзеңнән сүзең яхшы. Бәйләүче чараның синонимик вариантын күрсәтегез
шуңа күрә, әмма, ләкин
бары тик, ә, әмма
ләкин, ә, мәгәр

7. Контрольная работа

Хикәяне укыгыз. Аның буенча төзелгән биремнәрне үтәгез.

Каенкай

1) Урта полосаларда шаулап үскән ап-ак кәүсәле, ямь-яшел яфраклы каен агачы борынгы заманнардан ук тормышта үзенчәлекле урын алып килгән. 2) Билгеле булганча, кешеләр, төрле авырулардан котылу чарасын эзләп, агач һәм үлән яфракларын җыеп кайната һәм шулардан бик күп төрле дарулар әзерли торган булганнар. 3) Искиткеч шифалы булуы белән халык медицинасында үзенә аерым урын алып килгәнгәдер, каен турында татар халкында элек-электән үк бик күп истәлекле тарихи легендалар яшәгән.

4) Шуларның берсен күренекле Казан галиме К.Ф.Фукс язып алган. 5) Борынгы Болгар дәүләте белән Айдар хан хакимлек иткән чорда, Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең өч илчесен, могҗизалар күрсәтерлек бөтен кирәк-яраклар белән тәэмин итеп, Идел буена озаткан. 6) Алар һәртөрле авыруларга каршы көрәштә яшь каен яфрагын файдаланганнар.

7) Әйтергә кирәк, каен яфрагының дәвалау үзенчәлеге халык медицинасында шактый киң таралган. 8) Салкын тигән, томау төшкән кеше мунчага каен себеркесе алып бара һәм тәненә савыгу ала. 9) Фәнни медицина казанышлары өйрәткәнчә, каен бөреләренең дә тере организм өчен файдасы бар. 10) Мәсәлән, язын аның бөреләрен җыеп кайналар да алынган суы белән эчәк, ашказаны авыруларын дәвалыйлар. 11) Борынгы бабаларыбыз каенның менә шундый үзенчәлекләреннән файдаланганнар. 12) Каен суының шифалы булуы бик табигый, чөнки аның составында виноград шикәре, төрле кислота һәм тозлар бар. 13) Багдад илчесе Ибне Фазлан язмаларында, мәсәлән, болгарларның каен суыннан тәмле һәм шифалы эчемлекләр ясаулары да әйтелә.

14) Яз җитеп, җирдәге кар эри башлауга, каен кәүсәсенә татлы су җыела. 15) Бу вакытта яфраклар булмау сәбәпле, туфрактан алынган су парга әйләнми, өстәвенә аның тышкы ягы су һәм һава үткәрми торган кайрылар (каен тузы) белән дә капланган. 16) Галимнәрнең тикшерүенчә, шунысы игътибарга лаек: каенда углеводлар, башка үсемлекләрдәге кебек, яфрактан тамырга түгел, киресенчә, тамырдан яфракка хәрәкәт итәләр. 17) Бу исә каен суындагы күп кенә үзенчәлекләрне дә тәшкил итә.

18) Каенның табигать өчен әһәмияте зур. 19) Тирә-якка җәелгән каен урманнары туфрак дымын даими тоталар һәм, ул гына да түгел, җирдәге су алмашынуын тәэмин итәләр. 20) Җырларда җырланып, телләрдә макталган каен агачы әнә шундый кыйммәтле үзенчәлекләргә ия. 21) Янәшә-тирәдәге каен урманнары, димәк, безнең өчен иң яхшы һәм иң арзанлы "санаторий"лар. 22) Аларны кадерләп сакларга, булмаган урыннарда булдырырга кирәк. (К. Дәүләтшиннан).

1. Текстан кушма җөмләләрне күчереп языгыз.
2. 12 нче һәм 13 нче җөмләләрдән иярүче һәм ияртүче сүзләре исемнәр белән белдерелгән сүзтезмәләрне языгыз.
3. Аерымланган рәвеш хәле булган җөмләләрнең номерларын языгыз.
4. 3, 14, 22нче җөмләләргә тулы характеристика бирергә.
5. Кереш сүзләр булган җөмләләрне күчереп язарга.
6. 2нче җөмләгә тулы синтаксик анализ ясарга.
7. 3, 16 җөмләләргә тулы характеристика бирегез, схемасын төзегез.

8. ПЕРЕЧЕНЬ ПРИМЕРНЫХ ВОПРОСОВ И ЗАДАНИЙ:

1.Сложное предложение и его современная классификация.
3. Строение текста.

4. Суперсинтетические предложения.

5. Основные особенности сложносочиненных предложений.

6. Синтетический вид сложноподчиненного предложения.

7. Сложносочиненные предложения, образованные с помощью союзов перечисления

8. . Сложносочиненные предложения, образованные с помощью противительных союзов.

9. Сложносочиненные предложения, образованные с помощью разделительных союзов.

10. Сложносочиненные предложения, образованные с помощью интонаций перечисления и противопоставления.

11. Прямая речь.

12. Знаки препинания в сложносочиненных предложениях

13. Основные особенности сложноподчиненных предложений.

14. Общая характеристика главного и придаточного предложений.

15. Обособление синтетических предложений.

16. Аналитический вид сложноподчиненного предложения.

17. Аналитические сложные предложения , образованные с помощью союзов и союзных словю

18. Косвенная речь.

19. Аналитические сложные предложения , образованные при помощи парных местоименных слов.

20. Аналитические сложные предложения , образованные при помощи одиночных местоименных слов.

21. Аналитические сложные предложения , образованные при помощи интонации.

22. Синтетическое сложное предложение и полупредикативный оборот.

23. Синтетические предложения, связанные с главным при помощи аффиксов.

24. Синтетические предложения, связанные с главным при помощи послелогов и послеложных слов.

25. Синтетические предложения, связанные с главным при помощи обязательного соседства.

26. Порядок расположения аналитических и синтетических придаточных предложений по отношению к главному.

27. Синонимия между аналитическими и синтетическими придаточными предложениями.

28. Сложные предложения с придаточной частью вводных и вставных конструкций.

29.Функциональные типы сложноподчиненных предложений.

30. Сложные предложения с придаточной частью подлежащего

31. Сложные предложения с придаточной частью сказуемого.

32. Сложные предложения с придаточной частью определения.

33. Сложные предложения с придаточной частью дополнения

34. Сложные предложения с придаточной частью пояснения.

35. Синтетический вид придаточного предложения образа действия

3.Аналитический вид придаточного предложения образа действия

37. Сложные предложения с придаточной частью меры и степени

38. Сложные предложения с придаточной частью времени

39. Сложные предложения с придаточной частью места.

40. Сложные предложения с придаточной частью причины.

41. Сложные предложения с придаточной частью цели

42. Сложные предложения с придаточной частью условия.

43. Сложные предложения с придаточной частью уступительности

44. Сложные предложения с придаточной частью обстоятельств.
45. Сложноподчиненные предложения аналитическо-синтетической структуры.
46. Виды сложных предложений усложненной структуры
47. Сложные предложения с множеством сочинительной связи
48. Сложные предложения с множеством подчинительной связи
49. Сложные предложения смешанного типа.
50. Знаки препинания в сложных предложениях

МИНОБРНАУКИ РОССИИ
ФГБОУ ВО «Башкирский государственный педагогический университет
им. М. Акмуллы»

Институт филологического образования и межкультурных коммуникаций

ФОНД ОЦЕНОЧНЫХ СРЕДСТВ

Б1.В.02.04 СОВРЕМЕННЫЙ ТАТАРСКИЙ ЛИТЕРАТУРНЫЙ ЯЗЫК. МОРФЕМИКА. МОРФОНОЛОГИЯ. СЛОВООБРАЗОВАНИЕ.

для направления подготовки

44.03.05 Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)
направленность (профиль) «Родной (татарский) язык, литература и английский язык»

квалификация выпускника: бакалавр

4. Целью дисциплины является *развитие профессиональных компетенций*:

ПК-1 готовностью реализовывать образовательные программы по учебному предмету в соответствии с требованиями образовательных стандартов;

ПК-4 способностью использовать возможности образовательной среды для достижения личностных, метапредметных и предметных результатов обучения и обеспечения качества учебно-воспитательного процесса средствами преподаваемого учебного предмета.

ОЦЕНОЧНЫЕ СРЕДСТВА ДЛЯ ПРОВЕРКИ СФОРМИРОВАННОСТИ КОМПЕТЕНЦИИ

9. ТЕСТОВЫЕ ЗАДАНИЯ

Күрсәтелгән билгеләрнең кайсысы агглютинатив телләр өчен хас түгел?
{~кушымчаларның тамырга бер-бер артлы ялгануы
~һәр кушымчаның үзаллы грамматик мәгънәсе булу
~фигыль белән белдерелгән кисәкнең җөмлә башында килүе
~сүз тамырының тотрыклы булуы}

Бер үк сүз нигезенең күп төрле грамматик формаларда килүе нинди термин белән атала?
{~грамматик мәгънә
~лексик мәгънә
~морфема
~парадигма}

Ялгыз *ял күрмәс,* ***күмәк*** *ару белмәс* (мәкаль) җөмләсендә нинди күренеш күзәтелә?
{~сыйфатларның исемләшүе
~хәлләрнең аерымлануы
~иянең төшеп калуы
~аергычларның тиңдәшләнүе}

Сусыл, моңсу сүзләрендә -сыл һәм -су кушымчалары:
{~сыйфат дәрәҗәсе ясый
~яңа сүз ясый
~сүзне төрләндерә
~сүзне үзгәртми}

Кайсы исем фигыль тамырыннан ясалган?
{~кунак
~беләк
~колак
~аяк}

Күрше-күлән сүзенең нигезенең төре:
{~тамыр
~тезмә
~парлы
~саф}

Модаль мәгънә белдерү – ул
{~сөйләгәндә сөйләүченең чынбарлыкка төрле мөнәсәбәттә торуын белдерү

~төшенчәләр арасында төрле мөнәсәбәтләрне белдерү
~сүз ясау
~бәйләүче ролен үтәү}

Сүзчән сүзе ясалышы буенча
{~ясалма
~тамыр
~парлы
~кушма}

Парлы сүзләр нинди берәмлекләргә нигезләнеп барлыкка килгәннәр?
чит-ят, бата-чума, әйләнә-тулгана
{~омоним
~антоним
~пароним
~синоним}

Морфема ул –
{~сүзнең иң кечкенә мәгънәле кисәге
~тел белеменең бер тармагы
~грамматик категория
~сүзнең тамыры}

Тамыр ул –
{~төп лексик мәгънәне белдергән мәгънәви кисәк
~лексик-грамматик мәгънә белдергән кисәк
~саф грамматик мәгънә белдергән кисәк
~аның мәгънәсе юк}

Аффикс ул –
{~төп лексик мәгнәне белдергән мәгънәви кисәк
~лексик-грамматик яки саф грамматик мәгънә белдергән кисәк
~аның мәгънәсе юк
~тамыр белән тәңгәл килә}

Китапларыңа сүзендә ничә морфема?
{~4
~2
~3
~5}

Агглютинатив телләрдә кушымчалар
{~тамырга бер-бер артлы тагылып килә
~аерым языла
~булмыйлар
~тотрыклы бербөтен тәшкил итәләр}

Нуль морфема булган тезмәне тап:
{~бала уйный
~зәңгәр чәчәк
~күп эшли
~балалар уйныйлар}

Кайсы билгеләмә татар телендәге тамыр терминына туры килми?
{~тамыр тотрыксыз, үзгәрә ала
~лексик мәгънә белдерә торган кисәк
~төп мәгънәне саклаган хәлдә ваграк кисәкләргә таркала алмый торган кисәк
~сүзнең төрле формалары өчен уртак булган кисәк}

Түбәндәге юлларны кем әйткән: «Тамыр кисәк, үзгәртелмәгән көенчә, башка бик күп төрле кушымчалар белән дә йөртелә алырга тиеш; мәсәлән, ***эш*** дигән тамырын без *эшлә, эшсез, эшчән, эшлекле, эшләткән, эштән*... кебек һәртөрле кушымчалар белән дә әйтелә алганлыгын күрәбез. Тамыр кисәкнең кушымча белән бергә әйтелгән чагында аңлаткан төп мәгънәсе ялгыз гына әйтелгән чагында да югалмаска һәм үзгәрмәскә тиеш. Югыйсә ул сүзнең тамыры булып саналмаячак. Мәсәлән, ... *утыр, сукыр, тимер* кебек сүзләрнең азагында ... *-ыр, -ер* кисәкләре кушымча булып санала алмыйлар. Чөнки ... бу кисәкләрне алгач, югарыда калган кисәкләрнең элгәреге мәгънәләре калмый»
{~Г.Алпаров
~А.Кайдаров
~А.Шайхулов
~Ж.Киекбаев}

Татар телендә тамыр аерым кулланылганда
{~грамматик яктан да формалашкан була, ягъни сүз тамыр хәлендә үк билгеле бер сүз төркеменә карый
~тамырның кайсы сүз төркеменә керүен һәрвакытта да билгеләп булмый
~тамыр эчендә төрле фонетик чиратлашулар күзәтелә
~төрле сүз төркеменә карарга мөмкин}

Агглютинатив телләрдә бер кушымча
{~бер генә мәгънә белдерә
~берничә мәгънә белдерә ала
~ул мәгънә белдерми
~икенчесен ачыклап килә}

Кемнең хезмәтләрендә кушымчалар өч төркемгә: сүзясагычлар, төрясагычлар һәм төрләндергечләргә бүленә?
{~В.Хангилдин
~Д.Тумашева
~Г.Алпаров
~Г.Ибраһимов}

Татар тел белемендә соңгы елларда чыккан хезмәтләрдә кушымчалар ничә төркемгә бүленә?
{~2
~3
~1
~4}

Бәйләгеч кушымчалар
{~җөмләдә сүзләр арасындагы төрле мөнәсәбәтләрне белдерәләр
~җөмләдә сүзләр бәйләнешен барлыкка китермиләр
~төрле грамматик формаларны ясыйлар
~модальлекне белдерәләр}

Исемдә килеш, тартым, хәбәрлек кушымчалары
{~төрләндергеч кушымчалар
~сүзясагыч кушымчалар
~төр ясагыч кушымчалар
~алар тамыр составына керәләр}

Фигыльдә заман кушымчасы
{~төрләндергеч кушымча
~сүзясагыч кушымча
~төр ясагыч кушымча
~кисәкчә була}

Күтәрелә, күтәрешә, күтәртә сүзләрендә кушымчалар
{~форма ясый
~сүз ясый
~сүзне төрләндерә
~модальлек белдерә}

Сүз формалары эчендә морфемаларның конкрет реальләшүен ничек атыйлар?
{~алломорфлар
~вариантлар
~коррелятлар
~семантик оя}

Ватык, китек, төзек сүзләрендә кушымчалар
{~продуктивлыгын югалткан
~продуктив
~үле
~тере}

Нинди кушымчалар үле кушымчалар була?
{~борынгы тамыр белән берегеп киткәннәр
~язма истәлекләрдә генә очрыйлар
~алар әле дә кулланылышта йөриләр
~алар 1-2 сүздә генә табылырга мөмкин}

Фузия күренеше ул –
{~тамырның варитивлыгы
~тамырның тотрыклылыгы
~тамырның кыскалыгы
~тамырның озынлыгы}

Төнбоеклар сүзенең нигезе:
{~кушма
~тамыр
~тезмә
~ясалма}

Каен җиләге –
{~кушма нигез
~фразеологик берәмлек

~сүзтезмә
~эпитет}

Балакай-бәләкәй, тау-дәү кебек сүзләрнең ясалыш ысулы нинди?
{~фонетик
~морфологик
~конверсия
~лексик-семантик}

Күз (глаз), *күз* (петля); *йомгак* (клубок), *йомгак* (итог); *түгәрәк* (круглый, круг), *түгәрәк* (кружок) сүзләрнең ясалыш ысулы нинди?
{~синтаксик
~морфологик
~конверсия
~лексик-семантик}

Кис-кеч, сөз-геч, төй-геч, сөрт-кеч сүзләрендә сүзъясалыш мәгънәсе
{~корал
~субъект
~объект
~профессия}

Бер үк сүз төркеменнән бер үк кушымча белән ясалган, бер үк сүз ясалыш мәгънәсенә ия булган сүзләр
{~бер сүз ясалыш тибына карыйлар
~бер сүз ясалыш моделенә карыйлар
~бер сүз ясалыш ысулына карыйлар
~бер сүз ясалыш нигезенә карыйлар}

Бер үк ясагыч нигездән төрле кушымчалар белән сүзләр ясалу –
{~сүз ясалыш оясын барлыкка китерә
~бер сүз ясалыш тибын барлыкка китерә
~бер сүз ясалыш моделен барлыкка китерә
~бер сүз ясалыш ысулын барлыкка китерә}

Бер үк тамырга бер-бер артлы берничә ясагыч кушымча ялганып сүз ясалу
{~сүз ясалыш чылбырын барлыкка китерә
~сүз ясалыш тибын барлыкка китерә
~сүз ясалыш моделен барлыкка китерә
~сүз ясалыш ысулын барлыкка китерә}

Яш(ел) ~чә~че~лек, бак(ча)~чы~лык, шак~ылда~ вык, гөр~лә~век, бил(ге)~сез~лек сүзләрендә һәрберсендә нинди күренеш?
{~сүз ясалыш чылбыры
~сүз ясалыш калыбы
~сүз ясалыш рәте
~сүз ясалыш оясы}

Нигез кыскару ничек атала?
{~аббревиация
~ассимиляция
~конверсия

~аффиксация}

Аффиксация – ул
{~морфологик ысул белән ясагыч кушымчалар ярдәмендә яңа сүзләр ясау
~бер сүз төркеменең икенчесенә күчүе
~сүзләрне кушу
~мәгънәне үзгәртү}

-лы/-ле; -гы/-ге; -чан/-чән; -ык/-ек; -гын/-ген нинди кушымчалар?
{~сыйфат ясагыч типик кушымчалар
~исем ясагыч типик кушымчалар
~төр ясагыч кушымчалар
~төрләндергечләр}

-ча/-чә (татарча, минемчә, синеңчә); -дай/-дәй (уттай, төлкедәй, синдәй); -лай/-ләй (бушлай, яшьләй, тереләй); -лата/-ләтә (онлата, акчалата, икеләтә); -ын/-ен (көзен, кичен, җәен) кушымчалары ярдәмендә нинди сүз төркеме ясала?
{~рәвеш
~сыйфат
~исем
~хәл фигыль}

Кайсы галим татар телендә сүз ясалышы буенча хезмәтләре белән танылган?
{~Ф.А.Ганиев
~М.З.Зәкиев
~И.С.Насипов
~В.А.Богородицкий}

Чуар тавык –
{~сүзтезмә
~тезмә сүз
~фразеологик әйтелмә
~кушма нигез}

Бал корты –
{~сүзтезмә
~Тезмә сүз
~Фразеологик әйтелмә
~Ике лексик берәмлек}

10. ПРИМЕРНЫЕ ЗАДАНИЯ, ДЛЯ ПРОВЕДЕНИЯ ПРОМЕЖУТОЧНОЙ АТТЕСТАЦИИ:

Бирем 1. Билгеләнгән сүзләргә сүз составы буенча (морфемик) анализ ясагыз.

Бераздан тынычлана төшкәч, Гасыйм Сәләхович уйлана башлады. Кызганычка каршы, улының “бернәрсә белмисең” дигән сүзләрендә дөреслек юк түгел иде. Бигрәк тә тормыш мәсьәләсендә һәм хәзерге яшьләрне **аңлауда**... Нигә ул алай, тормыштан бөтенләй үк аерылган кеше дә түгел ләбаса! Бөтен үзгәрешләрне, **яңалыкларны** күреп тә тора шикелле... Ләкин үзе дә сизә, нәрсәнедер белеп җиткерми, аңлап җиткерми... Әйтик, кешеләрнең **көнкүрешләрен**... Сүз дә юк, кешеләр хәзер җиңелрәк тә, яхшырак та торалар, әмма шуның белән бергә, аларның килерләре тигезләнеп беткәне юк бит әле. Аерма шактый зур, мәсәлән, профессор алган 450-500 сум айлыкны бик күпләр алмыйлар ич әле. Ә шулай да 70 сум ала торган вахтерның яки уборщицаның кызы сиксән сумлык импортный сапожкиларны киеп йөри... Ничек итеп моны эшләргә мөмкин? Дөньяның чыгымы күп – ничек кенә **арттыра** алалар?.. **Баш җитәрлек** түгел. Әйтәләр инде, кеше хәзер яшәргә остарды дип.. Ни дигән сүз бу? Ничек аңларга ул “**остаруны**”? Берничә җирдә эшләүме? Хаклы һәм хаксыз премияләр алумы? Спекуляция белән шөгыльләнүме? Ниһаять, дәүләт милкен әкрен генә ташумы? Кайберәүләрнең әйтүенә караганда, “остару” дигән төшенчәгә бу “ысулларның” барысы да керә, имеш. Тик кеше кайда, кем булып эшләвенә карап, шул “ысулларның” берәрсен оста гына куллана икән. Ышансаң – ышан, ышанмасаң – юк, анысы синең эш. Гасыйм Сәләхович ул ысулларның берсен дә белми иде, әлбәттә. Бервакытта да бер тиен харам акча кермәде аңа. Хезмәт хакы аның һәрвакытта зур булды, **иркен-мул** гына яшәр өчен җитеп торды. Кайчандыр фән әһелләре халык арасында иң яхшы тәэмин ителгән катлаудан санала иде. Ә хәзер дөнья тигезләнеп бара шикелле... Һәрхәлдә, Гасыйм абзаң **ашаган-эчкәнне**, Гасыйм абзаң кигәнне һәркем диярлек ашый-эчә дә, кия дә. Хәтта уздырып та җибәрәләр; белеме юк, квалификациясе юк, ә машинасы бар. Әнә кая китте эшләр!

Хәерле булсын. Халыкның тормышы елдан-ел яхшыра икән, бу бик әйбәт, ул шулай булырга тиеш тә, тик әлеге харам “ысуллар” гына тамыр җәя **күрмәсен** иде. Гаять зарарлы нәрсә, кешене тәмам боза, җәмгыятьне имгәтә торган хәтәр нәрсә. Бигрәк тә яшьләргә күчә башласа, бик начарга әйләнеп китүе мөмкин. Ә аның симптомнары юк түгел. Акча яратучы, акча артыннан куучы яшьләр студентлар арасында да бар, кызганычка каршы. Менә шушы нәрсә Гасыйм Сәләховичны аеруча борчый да инде. Чөнки аның белүенчә, яшьләрдәге акчага, малга комсызлык һич тә нужадан түгел (иске мәгънәсендә нужа юк та ул), ә бик иртә, бик яшьли, әле кеше булып җитәргә дә өлгермәс борын рәхәт, иркен яшәргә омтылудан гына килә. Менә үз улы белән бәхәс-талаш шуның бик ачык бер мисалы түгелмени?

Әйе, улы аңа “син бернәрсә дә белмисең, па!” дигән гаеп ташлады. Ә ул бит менә утыз ел инде шул яшьләр арасында яши, шуларны укыта, тәрбияли. Нәрсәне белми соң ул? Яшьләрнең уйларын, хыялларын, **теләкләрен**, кыскасы, эчке рухи дөньяларынмы – шуны **күздә тотып** әйтәме Радик?.. Әйе, кырык ата баласының эчке дөньясын белеп бетерү гаять читен, мөмкин дә түгел диярлек. Бигрәк тә дүрт-биш ел саен алар алмашынып тора, берәүләре китә, икенчеләре килә (һәм гел генә үзгәреп килә), ә син һаман искечә каласың, һаман олая барасың, һәм табигый хәл – яшьләр гүя синнән ераклаша, син инде аларны томанлырак, ятрак итеп күрә башлыйсың Әйе, белүләре бик читен. Әмма белмим дип әйтергә дә аның хакы юк.

Әмирхан Еники “Тынычлану” хикәясеннән өзек

Бирем 2. Тәкъдим ителгән сүз ясалыш ысулларына унар мисал уйлап языгыз.
Морфологик ысул:

Синтаксик ысул:
Морфологик-синтаксик ысул:
Лексик-семантик ысул:
Фонетик ысул:

Бирем 3. Парлы сүзләрнең басымнарын дөрес куеп укыгыз. Бирелгән сүзләрне кулланып, жөмләләр төзеп языгыз.

кадер-хөрмәт
шау-шу
хәер-сәдака
ким-хур
ару-талу
әйләнү-(бәйләнү) тулгану
ярым-ярты
рәхим-шәфкать
шик-шөбһә
абына-сөртенә
чит-ят
бата-чума

МИНОБРНАУКИ РОССИИ
ФЕДЕРАЛЬНОЕ ГОСУДАРСТВЕННОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ
«БАШКИРСКИЙ ГОСУДАРСТВЕННЫЙ ПЕДАГОГИЧЕСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ ИМ.М.АКМУЛЛЫ»

Институт филологического образования и межкультурных коммуникаций
Кафедра татарского языка и литературы

Направление 44.03.05 Педагогическое образование
(с двумя профилями подготовки)

Уровень образования: бакалавриат

Направленность (Профиль) «Родной (татарский) язык, литература и английский язык»

ФОНД ОЦЕНОЧНЫХ СРЕДСТВ

ФИЛОЛОГИЧЕСКИЙ АНАЛИЗ ХУДОЖЕСТВЕННОГО ТЕКСТА

1. Цель дисциплины является формирование следующих профессиональных компетенций:

ПК-1 готовностью реализовывать образовательные программы по учебному предмету в соответствии с требованиями образовательных стандартов.

ОЦЕНОЧНЫЕ СРЕДСТВА ДЛЯ ПРОВЕРКИ СФОРМИРОВАННОСТИ КОМПЕТЕНЦИИ

Перечень вопросов для контрольной работы

1. Изобразительные средства в художественном произведении.
2. Интерпретация художественного текста.
3. Особенности употребления фразеологизмов в художественной речи.
4. Лингвистический анализ экспрессивности художественного текста.
5. Собственно-прямая и собственно-авторская речь.
6. Индивидуальный стиль писателя и художественного произведения.
7. Пословицы и поговорки в художественном тексте.
8. Национально-культурная значимость концептов.
9. Национально-культурная значимость слов и фразеологических единиц.
10. Лингвокультурологический аспект анализа художественного текста.
